**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_29__» __12__ 2023 ел.** **№ __332___**

«Союз-Агро» ҖЧҖнең авыл хуҗалыгы җирләренә су сибү өчен сугару челтәрен төзү өчен Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге чикләрендә линия объекты территориясен ызанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 45, 46 статьялары нигезендә «Союз-Агро» ҖЧҖ тәкъдимен карап, территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында карар бирә:

1. «Союз-Агро» ҖЧҖнең Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге чикләрендә урнашкан «Союз-Агро» ҖЧҖнең авыл хуҗалыгы җирләренә су сибү өчен линия объекты территориясен ызанлау проектын үз акчалары исәбеннән әзерләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.
2. Территорияне ызанлау проектын әзерләү тәртибе, сроклары һәм карап тоту турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә карау өчен җибәрергә. Территорияне ызанлау проектын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турындагы тәкъдимнәрне караганда, әлеге тәкъдимнәрне керткән физик һәм юридик затларны чакыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов